ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**31.01.2020**

Зеленодольск
шәһәре

**КАРАР**
**№ 150**

Татарстан Республикасы Зеленодольск шәһәрендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр бәясен раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Җирләү һәм күмү эше турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирләү һәм күмү эше турында» Федераль законны гамәлгә ашыру чаралары турында» 2007 елның 18 маендагы 196 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2020 елның 29 гыйнварындагы 61 номерлы карары нигезендә «2020 елда түләүләр, пособиеләр һәм компенсацияләр индексациясе коэффициентын раслау турында» 2020 елның 29 гыйнварындагы 61 номерлы карары нигезендә Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. 2020 елның 1 февраленнән җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен Зеленодольск шәһәрендә 1 нче кушымта һәм 2 нче кушымта нигезендә 6 124,86 сум күләмендә билгеләргә һәм гамәлгә кертергә.
2. 2020 елның 1 февраленнән «Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районында җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр бәясен раслау турында» Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 31 гыйнварындагы 234 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.
3. «Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районында җирләү буенча хезмәт күрсәтүләрнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен раслау турында» 2019 елның 31 гыйнварындагы 234 номерлы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2019 елның 28 мартындагы 756 номерлы Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының карарын үз көчен югалткан дип танырга.
4. Әлеге карарны Интернет челтәрендә Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан

Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмат сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru)урнаштырырга һәм «Зеленодольская правда» газетасында бастырып чыгарырга.

5. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам..

Җитәкченең беренче урынбасары А.В. Старостин

Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 31 гыйнварындагы 150 номерлы карарына 1 нче кушымта

Татарстан Республикасы Зеленодольск шәһәрендә 01.02.2020 елдан җирләү буенча хезмәтләр күрсәтүнең гарантияләнгән исемлеге бәяләре

| **Хезмәт күрсәтү исеме** | **Хезмәт күрсәтү бәясе *(сумнарда)*** |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү. | 0,00 |
| 2. Табут һәм җирләү өчен башка кирәкле әйберләрне тәкъдим итү һәм китереп бирү | 3337,75 |
| 3. Зиратка үлгән кешенең мәетен (җәсәден) алып бару | 950,81 |
| 4. Җирләү (кабер казу һәм күмү ) | 1836,30 |
| **Барлыгы** | **6124,86** |

Зеленодольск муниципаль районы
Башкарма комитетының 2020 елның
31 гыйнварындагы 150 номерлы карарына
2 нче кушымта

Татарстан Республикасы Зеленодольск шәһәрендә 01.02.2020 елдан җирләү буенча хезмәтләр күрсәтүнең гарантияләнгән исемлеге бәяләре

| **Хезмәт күрсәтү исеме** | **Хезмәт күрсәтү бәясе *(сумнарда)*** |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0,00 |
| 2.Гыйбәдәт киеме кидертү/ Кәфенләү | 589,69 |
| 3. Табут һәм җирләү өчен башка кирәкле әйберләрне тәкъдим итү һәм китереп бирү | 2748,06 |
| 4. Зиратка үлгән кешенең мәетен (җәсәден) алып бару | 950,81 |
| 5. Җирләү (кабер казу һәм күмү ) | 1836,30 |
| **Барлыгы** | **6124,86** |